Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл жирлеге составына керүче
Казаклар авылында гражданнар жыены нәтижәләре турында

**КАРАР**

18 ноябрь 2022 ел № 9

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 18 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар жыены нәтижәләре белән беркетмә төзелде: "Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл жирлегенең Казаклар авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларнын гаилә әгъзаларыннан гайре), 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

– Олы Елга авылы суүткәргеч магистраленең су задвижкаларын сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру (шартнамә буенча эшкә түләүгә);
– авыл җирлеге торак пунктларындагы урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);
– Олы Елга авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның юл өлешен кышын карап тотуга (кардан чистартуга) (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә);
– Саескан Тавы авылында контейнер мәйданчыгы ясау һәм төзекләндерү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
– Олы Елга авылында балалар мәйданчыгы төзү (инвентарь сатып алу, урнаштыру, шартнамә нигезендә эш хакы түләү);
- суәтем башнясын сатып алу, монтажлау һәм урнаштыру (килешү буенча эшләрне түләү);
- мотопомпа өчен янгын жиһазларе сатып алу.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Гражданнар жыены нәтижәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган жыенда катнашучылар исемлегенә 101 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 60 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 60 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Казаклар авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: "Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларында йөреп укучы студентлардан, беренче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

– Олы Елга авылы суүткәргеч магистраленең су задвижкаларын сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру (шартнамә буенча эшкә түләүгә);

– авыл җирлеге торак пунктларындагы урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);

– Олы Елга авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның юл өлешен кышын карап тотуга (кардан чистартуга) (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә);

– Саескан Тавы авылында контейнер мәйданчыгы ясау һәм төзекләндерү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

– Олы Елга авылында балалар мәйданчыгы төзү (инвентарь сатып алу, урнаштыру, шартнамә нигезендә эш хакы түләү);

- суэтем башнясын сатып алу, монтажлау һәм урнаштыру (килешү буенча эшләрне түләү);
- мотопомпа өчен янгын җиңнәре сатып алу.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам, 16а йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Мингалеев И.Н.